| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
| Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080 | Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080 |

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№________** **«___»___________2018 г.**

Территория-тармак килешүе төзү буенча комиссия төзү турында

Дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләренең Бөтенроссия һөнәри берлегенең Татарстан республика комитетының 2018 елның 5 июлендәге 207/17 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгы һәм Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләренең Бөтенроссия һөнәри берлеге Татарстан республика комитеты арасында 2019-2021 елга территориаль-тармак килешүе төзү буенча комиссия төзергә (алга таба - комиссия) һәм комиссия составын түбәндәге тәртиптә расларга:

| | | |
|---|---|---|
| Зарипов И.Ф. | - | Теләче муниципаль районы Башлыгы, комиссия рәисе; |
| Фәтхуллин А. Г. | - | Теләче муниципаль район Башлыгы урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары; |
| Мәхмүтов Ф. Р. | - | Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хаҗиев А.Г. | - | Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Яхин Р. Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Яруллин Р. Н. | - | Теләче муниципаль район Советының оештыру бүлеге башлыгы; |
| Закирова Г.И. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт секторы мөдире. |

2. Үз эшчәнлегендә комиссиягә гамәлдәге законнарга таянып эш итәргә.

3. Комиссиягә 2018 елның 15 августына кадәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгы һәм Россия Федерациясе дәүләт

учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләренең Бөтенроссия һөнәри берлегенең Татарстан республика комитеты арасында 2019-2021 елга территориаль-тармак килешүе проекты буенча күмәк фикер алышу уздырырга һәм документны эчтәлеге буенча тәкъдимнәр кертергә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.Г. Фәтхуллинга йөкләргә.

И. Ф. Зарипов